КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2022 ел, 27 декабрь г.Казань № 1428

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2025 елга кадәр Татарстан Республикасында сәламәтлек саклауны үстерү» дәүләт программасын раслау турында» 2013 ел, 1 июль, 461 нче карары белән расланган «2025 елга кадәр Татарстан Республикасында сәламәтлек саклауны үстерү» дәүләт программасына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2025 елга Татарстан Республикасы сәламәтлек саклау системасын үстерү» дәүләт программасын раслау турында» 2013 ел, 1 июль, 461 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2014 ел, 15 май, 319 нчы; 2014 ел, 10 декабрь, 966 нчы; 2015 ел, 30 октябрь, 821 нче; 2016 ел, 12 апрель, 215 нче; 2016 ел, 22 сентябрь, 674 нче; 2017 ел, 13 гыйнвар, 4 нче; 2017 ел, 13 февраль, 80 нче; 2017 ел, 26 июнь, 429 нчы; 2017 ел, 4 октябрь, 760 нчы; 2018 ел, 30 июль, 612 нче; 2018 ел, 2 август, 625 нче; 2018 ел, 20 декабрь, 1194 нче; 2018 ел, 20 декабрь, 1197 нче; 2019 ел, 6 июнь, 472 нче; 2019 ел, 30 декабрь, 1239 нчы; 2020 ел, 8 сентябрь, 809 нчы; 2020 ел, 15 декабрь, 1138 нче; 2021 ел, 25 июнь, 497 нче; 2021 ел, 28 июнь, 513 нче; 2021 ел, 26 июль, 650 нче; 2021 ел, 1 декабрь, 1162 нче; 2021 ел, 22 декабрь, 1263 нче; 2022 ел, 16 май, 451 нче, 2022 ел, 31 май, 506 нчы, 2022 ел, 30 июнь, 615 нче, 2022 ел, 19 июль, 696 нчы, 2022 ел, 31 октябрь, 1155 нче, 2022 ел, 14 декабрь, 1330 нчы, 2022 ел, 16 декабрь, 1353 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган «2025 елга Татарстан Республикасы сәламәтлек саклау системасын үстерү» дәүләт программасына (алга таба – Программа) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

«Сәламәтлек саклау системасын кадрлар белән тәэмин итү» 7 нче ярдәмче программасы паспортының «Ярдәмче программаны гамәлгә ашыруның көтелгән нәтиҗәләре» юлын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | |
|---|---|
| «Ярдәмче программаны гамәлгә ашыруның көтелә торган нәтиҗәләре | 2025 елга дәүләт һәм муниципаль медицина оешмаларында эшләүче табиблар белән халыкның тәэмин ителешен 10 мең кешегә 36,2;<br>2025 елда дәүләт һәм муниципаль медицина оешмаларында эшләүче урта медицина хезмәткәрләре белән тәэмин ителешне 10 мең кешегә 96,2;<br>халыкка беренчел медицина-санитария ярдәме күрсәтүче табиблар белән тәэмин ителеш 2025 елга 10 мең кешегә 19,7;<br>эшләүче белгечләрнең гомуми санынннан аккредитация процедурасы аша һөнәри эшчәнлеккә кертелгән белгечләр өлеше 2025 елга 84 процентка кадәр;<br>амбулатория шартларында медицина ярдәме күрсәтүче медицина оешмаларының табиблар белән комплектлылыгы (амбулатор шартларда медицина ярдәме күрсәтүче медицина учреждениеләрендә вазыйфаларның гомуми санынннан физик затлар биләгән вазыйфалар өлеше) 2025 елга 95,5 процент;<br>амбулатория шартларында медицина ярдәме күрсәтүче медицина оешмаларының урта медицина персоналы белән комплектлылыгы (амбулатор шартларда медицина ярдәме күрсәтүче медицина учреждениеләрендә вазыйфаларның гомуми санынннан физик затлар биләгән вазыйфалар өлеше) 2025 елгка 100 процентка кадәр;<br>Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы карамагындагы урта һөнәри белем бирү мәгариф оешмаларына керүче барлык абитуриентлар белән белгечләрне максатчан әзерләү һәм эшкә урнаштыру турында дүрт яклы шартнамәләр төзү;<br>онкология, йөрәк-кан тамырлары һәм аутоиммун авыруларны профилактикалауның, диагностикалауның һәм дәвалауның яңа ысулларын һәм чараларын эшләү, сәламәт озак яшәү, йогышлы авыруларны профилактикалау, диагностикалау һәм дәвалау;<br>медицина хезмәтләре күрсәтүче (медицина хезмәтләре күрсәтүне тәэмин итүче) югары медицина (фармацевтика) яисә башка югары белемле медицина оешмалары табибларының һәм хезмәткәрләренең уртача эш хакының һәм Татарстан Республикасында уртача хезмәт хакының |

| | |
|---|---|
| | чагыштырмасы 2025 елга 200 процентка кадәр;<br>урта медицина (фармацевтика) персоналының (медицина хезмәтләре күрсәтүне тәэмин итүче персоналның) уртача хезмәт хакы һәм Татарстан Республикасында уртача хезмәт хакы 2025 елга 100 процентка кадәр җиткерү;<br>гаилә гиперхолестеринемиясен ачыклауга тикшерелгән затлар (өлкәннәр һәм балалар) саны арту»; |

«Татарстан Республикасы сәламәтлек саклау системасының беренчел звеносын модернизацияләү» 14 нче ярдәмче программасында (алга таба – 14 нче ярдәмче программа):

14 нче ярдәмче программаның II бүлегендәге «Ядәмче программаның төп чаралары характеристикасы» бүлекчәсендә:

өченче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2021 - 2025 елларга беренчел медицина-санитария ярдәме күрсәтү тәртибендә каралган беренчел медицина-санитария ярдәмен күрсәтү өчен медицина эшләнмәләрен 5 820 берәмлек күләмендә алмаштыру һәм җиһазлап бетерү планлаштырылган, шул исәптән: 4 336 берәмлек медицина эшләнмәләре һәм таушалу белән бәйле 1 484 медицина эшләнмәсен яңадан җиһазлау.»;

дүртенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2021 елдан 2025 елга кадәр Татарстан Республикасы бюджеты акчалары хисабына алдагы җиһазларны демонтажлау эшләре башкарылачак, монтажлана торган медицина җиһазларын урнаштыру өчен бүлмәләрне 127 берәмлек күләмендә яңадан җиһазландыру һәм әзерләү белән: магнит-резонанс томографы - 4 берәмлек, рентген компьютер томографы - 24 берәмлек, стационар рентген аппараты - 28 берәмлек, маммограф - 37 берәмлек, флюорограф - 34 берәмлек.»;

14 нче ярдәмче программаның «Ярдәмче программа максаты, бурычлары, нәтиҗәләрен бәяләү индикаторлары һәм аны чаралары буенча финанслау» таблицасының 3 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | | | | | | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| Инвалидларның һәм сәламәтлекләренең мөмкинлекләре чикләнгән халыкның башка төркемнәренең махсус ихтыяҗларын исәпкә алып, беренчел медицина-санитария ярдәме күрсәтелә торган медицина оешмаларын, шулай ук үзәк район һәм район хастаханәләрен медицина ярдәме күрсәтү җиһазы белән тәэмин итү | 3.1. Медицина оешмалары паспортларын исәпкә алып, өлкәннәргә һәм балаларга беренчел медицина-санитария ярдәме күрсәтелә торган медицина оешмаларының, аларның аерымланган структур бүлекчәләренең, үзәк район һәм район хастаханәләренең матди-техник базасын медицина ярдәме күрсәтү тәртибе таләпләренә туры китерү, аларны медицина ярдәмен күрсәтү җиһазы белән җиһазлап бетерү һәм яңадан җиһазлау | ТР ССМ | 2013 – 2025 еллар | Беренчел медицина-санитария ярдәме күрсәтүче медицина оешмаларында 10 елдан артык файдаланылган медицина ярдәме күрсәтү җиһазы санын киметү, берәмлек | 578 | 565 | - | - | - | - | РФ бюджеты | 178 697,7 | 925 879,9 | 1073133,9 | 513 178,7 | 499 854,6 |
| | | | | | | | | | | | ТР бюджеты | 44 722,3 | 231 739,8 | 268 631,1 | 128 340,3 | 125 002,6»; |
| | | | | Амбулатория шартларында медицина ярдәме күрсәтүче бүлекчәләрдә әлеге төр җиһазларның гомуми саныннан 10 елдан артык файдалану срогы, процент | 0 | 0 | 19,8 | 15,2 | 14,1 | 11,4 | | | | | | |

14 нче ярдәмче программага 8 нче кушымтаны яңа редакциядә (карарга теркәләләр) бәян итәргә;

Программаның 2 нче кушымтасында:

«3 ярдәмче программа. «Дәүләти-хосусый партнерлыкны үстерү» бүлегенең исемен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3 нче ярдәмче программа. «Дәүләти-хосусый партнерлыкны үстерү. Сәламәтлек саклау өлкәсендә халыкара мөнәсәбәтләрне үстерү»;

«14 нче ярдәмче программа. «Татарстан Республикасы сәламәтлек саклауның беренчел звеносын модернизацияләү» бүлегенең 14.28 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| «14.28. | Амбулатория шартларында медицина ярдәме күрсәтүче бүлекчәләрдә әлеге төр җиһазларның гомуми санынан 10 елдан артык файдалану срогы | процент | - | - | - | - | 19,8 | 15,2 | 14,1 | 5 % |

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин